**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Өҗем авыл җирлеге Таш-Чишмә торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«29» март 2024 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, «2024 елда Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе турында» 29.11.2023 ел, № 1532 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлегенең Таш-Чишмә торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә Муниципаль районы Өҗем авыл җирлегенең Таш-Чишмә торак пунктында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Торак пункт территориясен төзекләндерү (Таш-Чишмә торак пункты территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агачлар һәм куаклар кисү, үләннәр чабу, транспорт хезмәтләре һәм эш өчен түләү));

3) Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (чишмәләр) (“Ташчишмә” чишмәсен төзекләндерү (материал сатып алу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

2) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тәртиптә тоту (Таш-Чишмә торак пунктының урам юлларын ремонтлау һәм каплау (вак таш сатып алу, урам юлларын ремонтлау һәм урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләргә түләү)).»

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлегенең Таш-Чишмә авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Өҗем авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Өҗем авыл җирлеге башлыгы Вәлиев А.Т.